**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турында» 2005 елның 9 сентябрендәге ПУ-366 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 11 гыйнварындагы ПУ-3 номерлы, 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2010 елның 14 октябрендәге ПУ-695 номерлы, 2010 елның 17 ноябрендәге ПУ-751 номерлы, 2011 елның 14 февралендәге ПУ-57 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-627 номерлы, 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы, 2013 елның 12 февралендәге ПУ-108 номерлы, 2015 елның 25 февралендәге ПУ-189 номерлы һәм 2015 елның 19 октябрендәге ПУ-998 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең дәүләт вазыйфалары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 нче кушымтада:

атамасында «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең дәүләт вазыйфалары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары» сүзләренә алмаштырырга;

икенче позициядә:

«Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәчесе» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары» сүзләрен өстәргә;

«Татарстан Республикасы Премьер-министры секретариаты җитәкчесе» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты эшләр идарәчесе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Премьер-министры секретариаты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты идарәсе, департаменты җитәкчесе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты идарәсе башлыгы, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы департамент җитәкчесе, Татарстан Республикасы

Президенты департаменты директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты идарәсе башлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты идарәсе башлыгы (югары вазыйфалар төркеме)» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче позициядә «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты бүлеге мөдире (бүлеге башлыгы)» сүзләрен Татарстан Республикасы Президенты Аппараты бүлеге мөдире, бүлеге башлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты бүлеге мөдире, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты бүлеге башлыгы (югары вазыйфалар төркеме), Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Матбугат хезмәте җитәкчесе, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе секретариаты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 25 декабрь
№ ПУ-1157